

Мордовиядә, ботен Россиядә тосле, Жинv конен лаеклы каршы алырга әзерлек чаралары оештырыла. Шулай, 24 апрельдә Саранск шәһәренен Жинv мәйданында Ботенроссия “Георгиевская ленточка” акциясе старт алды. “Үлемсез полк” йореше 2024 елда онлайн форматта vтәчәк. Тагы “Жинv тәрәзәсе”, “Хәтер бакчасы”, “Жинv диктанты” һәм башка, һәм башка Ботенроссия акцияләрендә регионыбыз катнаша. Жинv бәйрәме алдыннан ГТРК “Мордовия” каналында Боек Ватан сугышы ветераннары кыймматле истәлекләрен житкерәләр. Республикабызнын башка район мәктәпләрендә тосле, Ромоданово районы Алтар урта мәктәбендә торле чаралар vтеп килә. Берничәсе турында тvбәндә язабыз.

Алтар гомуми белем бирv урта мәктәбендә Боек Ватан сугышы елларында нацистлар һәм аларнын ярдәмчеләре тарафыннан совет халкына геноцид истәлегенә Бердәм гамәлләр коненә багышланган “Искерv срогы булмаган” батырлык һәм хәтернен бердәм дәресе мәктәп музеенда Наиль Хәйдар улы Исхаков vткәрде. Батырлык дәресе укучыларда Боек Ватан сугышында халкыбыз батырлыгы очен патриотик хисләр, хормәт һәм горурлык, милли, гражданлык vзанын, vз илебез тарихына сакчыл монәсәбәт формалаштыру максатында vткәрелгән. Бу конне 6 сыйныф укучылары Конешева Мәдинә һәм Кузяева Аиша Боек Ватан сугышы елларында оккупацияләнгән территориядә тыныч совет гражданнары турында шигырьләр яттан сәнгатьле иттереп укыдылар. 3 нче сыйныфта Бердәм гамәлләр коненә багышланган класс сәгате vткәрелә. Ә 24 апрельдә 8 сыйныфта 2021 елдан алып vткәрелә торган “Искерv срогы булмаган” Ботенроссия дәресе узган: кыскасы, Жинv конен лаеклы каршы алу максаты белән барлык сыйныфларда торле-торле чаралар, дәресләр vткәрелә.